РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2020 г. г. Альметьевск № 206

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Советының 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә җир салымы турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2014 елның 2 октябрендәге 141 номерлы, 2014 елның 19 ноябрендәге 151 номерлы, 2015 елның 6 маендагы 179 номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы, 2016 елның 8 ноябрендәге 49 номерлы, 2018 елның 31 маендагы 122 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 126 номерлы, 2019 елның 28 августындагы 166 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 189 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац естәргә;

«гражданнар күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр»;

1.2. 3 пунктның алтынчы һәм җиденче абзацларын, җиденче һәм сигезенче абзацлар дип санарга.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 январннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хәмидуллин Ф.Р.).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»

Зак. № 3774